


*Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы* *№ 7, февраль, 2024 ел*

Патриотизм и гражданственность

**Ватанпәрвәрлек яки патриотлык — туган иленә, халкына бирелгәнлек, үзеңнең эш - патриотлык белән ватаныңның һәм халкыңның мәнфәгатьләренә намуслы хезмәт итү принцибы.**

## Солдатта булган диләр...

Билен кысып буган, диләр,
Бигрәк уңган, диләр;
Әллә каян күренеп тора –
Солдатта булган, диләр.

Минем абыем Вахитов Ильяс Мәхмүт улы, 1980 елның 24 нче августында дөньяга килә. Әтнә районы Әйшияз авылында яши.1987 нче елда Әйшияз башлангыч мәктәбенә укырга керә. Анда өченче классны тәмамлаганнан соң, 1991нче елда Күәм урта мәктәбендә укый. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Әтнәдә укуын дәвам итә. Анда тракторист - машинист һөнәрен үзләштерә. 1999 нчы елның ноябрендә армия сафларына алына. 6 ай Североморскийда укуда була. Анда янгын сүндерү һөнәре буенча белем ала. Аннан соң Авианесущий крейсер "Адмирал Флота Советского Союза Кузнецов"ка кучерелә. Ул корабльдә су өстендә ике ел буе диңгезче булып хезмәт итә. Анда төрле куркынычсызлыклар булмасын өчен бик тырышып хезмәт күрсәтә. 2001нче елда туган ягына әйләнеп кайта. Кайткач, бераз колхозда эшләп ала. 2013 нче елда Әтнә районының янгын сүндерү бүлегендә эшли башлый. Армиядә алган белемнәре бу һөнәрне башкарырга ярдәм итә. Бу бик җаваплы да, ушул ук вакытта авыр да, игелекле дә һөнәр. Төрле авыр ситуацияләр белән очрашырга туры килә, ди абыем. Бу эштә бик җитез, зирәк, кыю булырга кирәк. Кечкенә генә төгәлсезлек тә зур фаҗига тудырырга мөмкин. Ильяс абый уз эшен бик яратып башкара. Нинди кеше батыр була, дип сорасалар, мин һичшиксез, минем абыем дияр идем. Ул бик батыр йөрәкле, кешелекле. Мин абыем белән горурланам. Хәвеф-хәтәрләр булмасын, исән-сау эшләсеннәр дигән теләктә калам.



Шакирова Зәринә, 7 нче сыйныф укучысы

## Кем ул патриот?

Минемчә, патриот ул - туган иленә булган мәхәббәтен, патриотлык хисен изге бурыч аша үтәүче кеше. Ул - ил сакчысы! Безнең тыныч тормышыбызны саклаучы!

Ил сакчысы! Туган ил сакчысы! Бу сүзләрне ишеткәч, уйланып куям. Туган ил бит ул - мин, минем гаиләм, минем туганнарым, минем туган авылым, мин яшәгән җир. Димәк, илне саклаучылар безнең тынычлыгыбыз өчен үзләрен аямый хезмәт итәләр. Безнең халык элек - электән туган ил алдындагы бурычларын намус белән үтәгәннәр, ил чакырса, кулларына корал тотып, Ватан сагына басканнар. "Туган ил өчен" дип, сугышка кергәннәр, гомерләрен биргәннәр. Һәрберсе ил алдындагы изге бурычны батырларча үтәгән.

Әлегә кадәр яшьләр хәрби хезмәткә барырга ашкынып тормый иде. Күбесенең бармый каласы килде. Ә бит элегрәк хәрби хезмәткә бармаган егетләрне бирәү дә хөрмәт итмәгән, кызларда аларга кыек караган. Бүгенге көндә яшь егетләребезнең нинди батырлыклар күрсәтеп, намус белән илебезне саклауларын күреп, куанам мин, фикерем дә үзгәрде. Без алардан үрнәк алабыз. Киләчәктә дә илебезне сакларбыз дип ышандырабыз.Мин үзем белгән хәрби хезмәтне сайлаучы, офицер гаилә дустыбыз турында горурланып: "Менә ул - ил сакчысы" – дип әйтә алам. Ул чын мәгънәсендә патриот! Сүз мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызының бердәнбер улы - Сөнгатов Марат Марсель улы турында.

Әдәбият дәресе бара. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы, безнең яраткан апабыз - Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы тәрәзәгә күз сала да:

" Укучылар, нинди матур безнең туган яклар, сез шундый гүзәл табигатьле, тыныч илдә яшәвегез белән бәхетле. Үсеп житәрсез дә, сез дә туган ил чикләрен сакларга хәрби хезмәткә китәрсез. Әти-әниләрегез сезнең белән горурланыр. Туган илне саклау – һәрберебезнең изге бурычы" – ди. Әлбәттә, бу күбрәк егетләргә бирелгән киңәш.

Апабыз бу сүзләрне әйткәндә, үзенең Ерак Көнчыгышның Приморье өлкәсе Уссурийск шәһәрендә хәрби офицер, улы, Маратны искә төшерәдер. Марат-аның бердәнбер улы. Без апабызга гел бер сорауны бирәбез: " Ул сезнең бер генә бөртек балагыз, ни өчен аңа хәрби офицер һөнәрен сайларга рөхсәт иттегез". Ул моңсу гына, ләкин бик горурланып:" Ул һөнәрне үзе теләп, илне сакларга телим дип сайлады"- дип җавап бирә. Егетләребезнең күзләре очкынланып китә, укып бетергәч, күбесе хәрби хезмәтне сайлау фикере белән, әдәбият дәресеннән, күтәренке күңел белән чыгалар.

Мәктәптән кайтканнан соң, дәү әниемннән Марат абый турында сөйләвен үтенәм. Яныбызга бабаем да, сеңлем дә килеп утыра. "Маратның бу һөнәрне сайлавына нәсел шәҗәрәсендә хәрби кешеләр булуы да этәргеч бирми калмагандыр. Аның бабасы, Йосыпов Зөлкарь запастагы офицер иде. Йосыпов Марат ( бабасының апасының улы) Мәскәүнең югары артеллерия институтын бетергән. Казан артеллерия училищесында укытып, отставкадагы майор. Йосыпов Ирек (әнисенең

энесе) – милиция капитаны. 25 ел стажы бар. Казанда Мәскәү районы эчке эшләр бүлегендә хезмәт иткән, хәзерге вакытта пенсиядә. Ул иң беренчеләрдән булып Чечняга җибәрелде, хәрби бәрелешләрдә катнашты. Чечня сугышы ветераны. "Батырлык өчен", "Ак крест" медальләре белән бүләкләнде. Бик тырыш егетләр барысы да "- дип безгә карашын юнәлтә. Сеңлем: "Ул ничек хәрби була алды икән?"- дип әйтеп куя. Дәү әнием:"Кызым, хәрби кеше булу өчен Марат абыең кебек тәртипле, чиста, пөхтә, сүз тыңлаучан, тыйнак, сабыр булырга кирәк. Ул бик оста рәссам, сызымнарны искиткеч төгәллек белән сыза, җырга, биюгә дә бик оста егет . Сез дә бик тырышып укы, тәртипле бул, эти-әниеңнең сүзен тыңларга өйрән илгә файдалы кешеләр булып үсегез, ди.

Мин үзебезнең авылда шундый кешеләр булу белән горурланам. Бигрәк тә Марат абыйның этием белән бер сыйныта укуы минем өчен зур шатлык.

**Халитова Илвинә, 6 нчы сыйныф укучысы**

## Ватанны саклау –изге бурыч



Армия…Гади генә тоелган бу сүз эченә тирән мәгънә салынган. Яп-яшь егеттән, кыю ир-атларга әверелеп кайта торган, чыныгу урыны ул. Менә шундый батыр ир-егетләр арасында минем этием дә булуы - безнең өчен зур горурлык.

Әтиебез - Багавиев Данис Римхәт улы 1991 елда хәрби хезмәткә алына. Хәрби хезмәт юлын ул, Азов диңгезе белән Кара диңгез кушылган урында урнашкан, герой шәһәр Керчьтә башлый. Ул анда алты ай белем ала, ягъни «учебкада» була. Башта самолетларның двигатален кабызу агрегатларында эшләргә өйрәнәләр. АПА - 5 (Аэродромный пусковой агрегат) дигән махсус кабызу машинасында эшләргә өйрәтәләр. Аннан соң, эти Марий Эл республикасы Йошкар Ола да хезмәт итә, ул хәрби аэродромда эшли. Самолет һәм вертолетларны техник хәзерлеген тәэмин итеп карап тикшереп торалар. Әтинең бүген дә армия истәлеге итеп күп санлы фотолары һәм куен дәфтәре - блокноты саклана. Анда истәлекләр, шигырьләр, җырлар һәм дуслары турында язылган язмалар һәм адреслар саклана.

Ул 1993 елның 12 октябрендә исән-сау туган авылына әйләнеп кайткан. «Армиядән чын ир егет булып кайтасын» , - ди этием.

Армиядә төшерелгән күп санлы фотографияләргә карап, этиемнең яшь чагын күрәм, яшь егет вакытын күзаллыйм. Мәктәптә хәрби патриотик ай кысаларында очрашулар уздырылды, күргәзмәләр оештырдык, конкурслар уза. Игелекле эшләребез дәвамлы булсын. Ил чикләре тыныч булсын. Тыныч тормышта яшәү зур бәхет.

**Багавиев Адель, 9 нчы сыйныф укучысы**




## Минем этием

Җир йөзендә минем иң якын кешеләрем – эти-әнием. Әни безгә үзенең назын бирсә, эти һәр яктан безгә терәк булып тора. Әтиләрнең канаты астында үзеңне көчле һәм иркен хис итәсең, яклаучың, саклаучың барлыгын тоясың.

Минем этием дә - бик яхшы, олы җанлы, әйбәт эти. Аның исеме - Илсур. Ул көн саен эштә. Үз эшен яратып башкара. Ул эштән арып кайтса да, безнең белән уйнарга, безгә булышырга көч һәм вакыт таба. Әнием белән бергә 22 ел яшиләр. Әтием әниемә дә яратып, матур сүзләр белән генә дәшә.

Әтием беркайчан да авырмасын иде, гел шундый әйбәт, игътибарлы , ягымлы эти булып калсын. Мин этиемне бик яратам.

**Борханова Инзилә, 3 нче сыйныф укучысы**

### Капитан абыем

Тимур абыем - капитан,

Йөзә Кара диңгездә.

Бик яратабыз аны

Өйдә бөтенебез дә .

Сагындым инде үзен

Ялга кайтам, ди көзен.

«5» кә укы, тырыш бул, ди

Тынлыймын аның сүзен.

**Садриева Ралия 1 нче сыйныф укучысы**

### Музейларда безнең тарих.....

Безнең мәктәптә "Туган якны " өйрәнү музее бар. Без 27 февраль көнне музейда кунакта булдык. Анда борынгы эш кораллары, йорт өчен кирәк - яраклары, сугыш чоры әйберләре, иске акчалар, төрле әйберләр белән таныштык. Миңа музейда бик күп әйберләр ошады. Элек чабаталар үргәннәр һәм кигәннәр икән. Ә апалар чиккән сөлгеләр, калфаклар, тәбәтәйләр бик матур булган. Туган як музеенда һәр предмет тарихны, борынгы чорны хәтерләтә. Без үткәнне онытырга тиеш түгел.

**Василов Азат 1 нче сыйныф укучысы**






## Әтием солдат булган.

Минем әтием 2010 нчы елда армиягә хезмәт итәргә киткән. Ул башта Чиләбе шәһәрендә укыту курсларында булган. Шунда хәрби хезмәт осталыгына өйрәнгән, нинди генә авырлыклар килсә дә, Туган илне сакларга ант биргән. Аннары Новосибирский олкәсендәге Берск шәһәренә җибәргәннәр. Ул рядовой солдат булып хезмәт иткән. Туган җирдән читтә яшәү авыр булса да, түзәргә кирәк. Ике арада йөргән, кайнар сәлам хатлары, очрашу көннәрен тагын да якынайта. 2011 нче елның көзендә әтием туган авылына әйләнеп кайта, аны барысы да бик сагынып көтеп алалар. Әтием әйтүенчә, элек армиягә бармый калу егет өчен хурлык саналган. Армиядә хезмәт итеп кайткан егетне генә чын ир дип санаганнар, ул шуның белән горурлана. Шунысы да бар: егетнең хәрби хезмәткә китүе аның сәламәт, көчле булуын күрсәтә. Хезмәт итү чорында җитди сынаулар үтеп, тормыш тәҗрибәсе туплап солдат егет физик кына түгел, рухи яктан да ныгып кайта дигән фикердә минем әтием.Мин Әтием белән бик горурланам!!!

**Закиржанова Дилия, 3 нче сыйныф укучысы**

## Күәмнәрдә минем туган җирем

21 февраль Халыкара туган телләр көне уңаеннан, мин Комыргуҗа мәктәбендә Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге фәнни-гамәли конференциясендә катнаштым. Быел ул 9 нчы тапкыр үткәрелә икән. Бу көн минем өчен бик истәлекле булды. Безне бик елмаеп каршы алдылар, милли ризыклар белән сыйладылар. Аннан Мәрҗани музеенда экскурсиядә булдык. Башка мәктәп укучылары белән таныштым.

Конференциягә әзерлек эше бер ай алдан башланды, чөнки быел аеруча җаваплы, 2 нче секциясе Самат Шакир мирасы буенча "Йөрәккә кучкән язулар" дип аталды.

Быел якташ шагыйрь Самат Шакирның тууына 100 ел. Шуңа күрә без аның иҗаты буенча әзерләндек. Бу секциядә 4 укучы катнаштык. Самат Шакирның "Эзтабар язучы – батырлык җырчысы", "Күәмнәрдә минем туган җирем", "Үтсен синдә гомерем, мин - синеке, и кадерле туган якларым", "Йөрәгемдә – җыр, кулымда – мылтык" дигән темалар буенча әзерләнү эшләре алып бардык.

Жюри 1 урынга мине лаек дип тапкан. Диплом һәм истәлекле бүләк алу – минем өчен дулкынландыргыч мизгел булды. 9 сыйныф укучысы Гөлия Кәлимуллина - 2 урын, 7 сыйныф укучысы Лилия Гатауллина һәм 8 сыйныф укучысы Азалия Мирхазианова 3 урынга лаек булдылар. Шул ук вакытта "Шиһабетдин Мәрҗани – «Таңыбызның Чулпаны" секциясендә Зөһрә Садриева Мәрҗанигә багышлаган эше белән катнашты. Укытучылар секциясендә Алия апа Садриева «Милләтем өчен тугры хезмәт итәм» дигән тема буенча тәҗрибә уртаклашып, 2 урынга лаек булды.

## Туган җирем (хикәя)

Һәр кешенең үз туган җире бар. Минем туган җирем ул – Күәм авылы. Биредә яшәвем белән бәхетлемен, туган җирем белән горурланам.

Күәм авылы Казан ханлыгы булган вакытта ук төзелгән. 1920 нче елларга кадәр Күәм 3 өлешкә бүленгән: Спочинок Күәме, Иске Күәм һәм Күәм. 1830 нчы елда авылда беренче мәчет төзелгән. 1832 нче елда икенче мәчет төзелә, ләкин 1936 елда аның урынына мәктәп төзелә.

Авылның атамалары күп, ләкин миңа 1648 нче елның маенда Күәм атамасы И.П.Ермолаев хезмәтендә теркәлгәне билгеле.

Элекке заманнарда Күәм, Әйшияз, Үртәм, Казак Үртәме, Күлле-Киме, Җигелде, Бактачы, Каенсар авыллары халкы бергә җыелып июнь аеның беренче декадасында Калатау исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Күәм атамасы нәрсә аңлата соң? Исемендә нинди сер саклый бу авыл?

Күәм авылының исеме Кобан, Куман, Каман юлы дигән атамалардан алынган.

Авыл бик матур җирдә урнашкан. Аны икегә бүлеп Күәм суы ага. Кояш чыгышында Таңатыр исемле агачлык күренеп тора. Авыл читендә Кала асты дигән урын бар. Анда изгеләр күмелгән дип сөйлиләр, янында гына Изгеләр чишмәсе ага. Авылның икенче читендә Казаклар дип йөртелгән елга бар. Күәм авылы зур, бер башыннан икенче башына кадәр 3 чакрымга сузыла. Революциягә кадәр авылда 4 мәчет булган. 1930 нчы елда мәчетләрнең манараларын кисканнәр. Бер мәчет мәдәният сарае итеп үзгәртелгән, калганнары юкка чыккан.

Авыл халкы чыпта суккан, чабата үргән, шулай итеп көн күргән.

Авылда 6 җил тегермәне, 2 су тегермәне булган.

Күәм авылы, Иске авыл, Югары оч, Яңа урам, Тәтлек урамы, Башаяк, Аргы як, Түбән оч дигән өлешләргә бүленгән.

Авылда 5 зират бар: Казаклар зираты, Иске зират, Изгеләр зираты, Башаяк зираты һәм Яңа зират. Халык зиратларны карап һәм чистартып тора.

Мәктәптә авыл тарихына багышланган һәм Самат Шакир исемендәге музейлар бар. Авыл тарихына багышланган музейда укучылар тарафыннан җыйналган әйберләр урнаштырылган. Авыл тарихына багышланган альбомнар тутырылган, күренекле авылдашларның рәсемнәре куелган. Музей яңа экспонатлар белән тулылануын дәвам итә.

Авылда китапханә, зур мәдәният йорты, унберъеллык мәктәп, медпункт һәм балалар бакчасы бар. Хәзерге вакытта авылга газ кертелгән, асфальт, яңа кибетләр эшли һәм мәчет төзелгән. Авыл янара, яшәрә һәм үсә.

**Шакиров Раяз, 5 нче сыйныф укучысы**




**Галимжанова Әдилә, 7 нче сыйныф укучысы**